ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2022 г. Казань № 674-236/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» филиалы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 18.11.2022 №620-195/кс-2022 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 25 ноябрендәге 40-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, җайга салынулы оешманың атамасы үзгәрү сәбәпле, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» филиалы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 18.11.2022 №620-195/кс-2022 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елга «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» җитештерү районы аерымланган бүлекчәсе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында»;

1 пунктта «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» филиалыннан» сүзләрен «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» җитештерү районы аерымланган бүлекчәсе» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» филиалына» сүзләрен «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» җитештерү районы аерымланган бүлекчәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтада:

атамасында «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән

җәмгыятенең «Баулы» филиалыннан» сүзләрен «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» җитештерү районы аерымланган бүлекчәсе» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» филиалы» сүзләрен «Газпром теплоэнерго Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Баулы» җитештерү районы аерымланган бүлекчәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев